**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 июня 2026 ел № 193

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә ярдәм чаралары исемлеген раслау турында» 16.02.2023 №141 яңа редакциядә карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларында махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категория затларга ярдәм итүнең бердәм база чаралары турында» 15.05.2026 №327 Указына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә ярдәм чаралары исемлеген раслау турында» 16.02.2023 №141 карарына (02.11.2023 №769 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар исемен түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә ярдәм чаралары исемлеген раслау турында»;

1.2. карар преамбуласында «катнашучы» сүзен «катнашучы (катнашкан)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм чараларының кушымтада бирелә торган исемлеген расларга.»;

1.4. махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм чаралары исемлегенең 1, 2, 4-6 пунктларында «катнашучы» сүзен «катнашучы (катнашкан)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес

буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Контроль за исполнением настоящего решения оставляю за собой.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ * ИНН 1610001536 КПП 161001001 ОГРН 1061685002510